

Быел Мордовия парламен-таризмнын 31 еллыгын билгеләп vтә. Истәлекле дата алдыннан РМ Дәvләт Жыелышында Саранск дәvләт сәнәгать-икътисад коллияте студентлары очен парламентаризм дәресе узды.

Мордовия Дәvләт Жыелышы (Госсобрание) рәисе урынбасары Наталья Долматова балаларга тобәк тарихы белән тыгыз бәйләнгән Мордовия парламенты тарихы, Дәvләт Жыелышынын тозелеше, парламент фракцияләре турында сойләде. Ул закон чыгару эшчәнлеге процессында ижтимагый институтлар белән ничек хезмәттәшлек итvләрен анлатты.

- Бvген Закон чыгаручылар очен остенлек - ул махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларнын якыннарына ярдәм итv. Сонгы вакытта депутатлар без-нен геройларга ярдәм кvрсәтvгә юнәлдерелгән тулы бер законнар пакеты кабул итте.

Тагын бер моһим юнәлеш балалы гаиләләрнен тормыш сыйфатын кvтәрvгә бәйле законнар булды, - дип билгеләде Наталья Владимировна.

Мордовия Республикасы Дәv-ләт Жыены Рәисе урынбасары ассызыклаганча, Мордовия һәм Россиянен киләчәге - кvп балалы гаилә.

Мордовиядә илдә аналоглары булмаган балалы гаиләләргә ярдәм итv чарасы эшли башлады. Хәзер гаиләдә бала туганда, сатып алу хокукы белән тvләvсез торак биреләчәк. Бу агымдагы елнын 1 ноябреннән 2027 елнын 1 ноябренә кадәр доньяга килгән нәниләрнен ата-аналарына кагылачак. Мондый хокуктан бюджет хезмәткәрләре, шулай ук дәvләт һәм муниципаль хезмәткәрләр файдалана алачак.

Мордовия Дәvләт Жыелышы каршындагы Яшьләр парламенты житәкчесе урынбасары Сергей Терешкин студентларга тобәк парламентынын яшьләр белән эшләv vзенчәлекләре турында сойләде. Анын сvзләренчә, Безнен тобәкнен Яшьләр парламентынын моһим vзенчәлеге - ана закон чыгару инициативасы хокукы бирv. Ул Мордовия яшьләренен vз хокукларыннан актив файдалануын искәртте. Республикада патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия турында тобәк законы эшләнде һәм кабул ителде. Олкән коллегалар каравына «Юридик затлар исемнәрендә «Мордовия Республикасы», «Мордовия» рәсми атамаларын куллану тәртибе турында» («О порядке использования в наименованиях юридических лиц официальных наименований «Республика Мордовия», «Мордовия») закон проектын кертергә тәкъдим ителде.

Викторина парламентаризм дәресенен кызыклы этабы булды. Саранск дәvләт сәнәгать-икътисад коллияте студентлары барлык биремнәрне дә унышлы башкарып чыктылар.